ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

от 29.01.2016 г. Казань № 10-1/кс

«Катлам басымын тоту өчен технологик сыеклыкәзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы «Катлам басымын тоту өчен технологик сыеклыкәзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә эчергә яраклы суга тарифларны билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2016 елның 1 мартыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүче һәм су бүлүне башкаручы «Катлам басымын тоту өчен технологик сыеклыкәзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 29.01.2016 № 10-1/кс
карарына кушымта

## «Катлам басымын тоту өчен технологик сыеклыкәзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчергә клендарь чорларына бүлеп эчергә яраклы суга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне башкаручы оешма | эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|
| | | 01.03.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | |
| 1 | «Катлам басымын тоту өчен технологик сыеклыкәзерләү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән), шул исәптән | | |
| 1.1 | Бөгелмә муниципаль районы кулланучылары | 24,36 | 25,66 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге